СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 281 от 30.07.2024
На № __________ от _____________

# КАРАР

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 2.3, 2.5. һәм 2.7 пунктларны төшереп калдырырга;

**1.2.** 2.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенә, еллык түләүле отпуск биргәндә айлык акчалата түләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләүләр, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык

җыелма күләме муниципаль район башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән 0,45 тән артмаска тиеш.».

**2.** Әлеге карарның гамәлдә булуын 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

**3.** Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р.Н. Минниханов